Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы

КАРАРЫ

03 март 2020 ел № 180

Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2016 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы 61 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында» 1996 елның 1 апрелендәге 27-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, 2020 елның 22 январендагы 30-пр номерлы Әлмәт шәһәре прокуратурасы протестын караганнан соң

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2016 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы 61 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2017 елның 27 сентябрендәге 93 номерлы, 2018 елның 17 июлендәге 127 номерлы, 2019 елның 06 маендагы 156 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче бүлекнең 2.5 пунктындагы өченче абзацны төшереп калдырырга;

1.2. 7 нче бүлекнең 7.1. пунктында:

а) 2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш ) яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында җирлек Советы мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

г) җирлек мәнфәгатьләрен идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә, гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) җирлек булган оешмаларда яклау, җирлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»

б) түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.1.) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки аша ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»

1.3. 9 нчы бүлекнең 9.3. пунктының 6 нчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ рәвешендә;».

1.4. 22 нче бүлекнең 22.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22.4. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.; »

1.5. 22 нче бүлекнең 22.6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22.6.5. Муниципаль хезмәткәрләргә коррупциячел хокук бозу турында мәгълүмат кергән көннән алып 8, 22, 24 пунктларында каралган түләтүләр муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә яраксыз булу чорларын, аның отпускта булуын исәпкә алмаганда һәм коррупциячел хокук бозу башкарылган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эше каралган вакыт кертелми.».

2. Әлеге карарны Түбән Мактама ш.т.б. һәм Тихоновка авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты "Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы бистә башлыгы В.Н. Михайлов